**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Нырты авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

«15» апрель, 2025 ел № 6

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун ел вакытка расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 19 апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән (kukmor.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә түбәндәге адресларда урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

Нырты ав., Мәктәп ур., 7 й.;
Төркәш ав., Үзәк ур., 42 й.;
Яңа Чәбия ав., Бакча ур., 55 й.

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Җирлек башлыгы: Т.А. Кутдусов

ОГРН 1021607754563
ИНН 1623001710

Татарстан Республикасы Кукмара районы Нырты
авыл җирлеге Советының 2025 елның 15 апрелендәге 6
номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы**

**1 номерлы бермандатлы Татарстан сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 76

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Нырты авылы (Татарстан урамының 5 - 35нче йортлары).

**2 номерлы бермандатлы Мәктәп сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 74

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Нырты авылы (Мәктәп урамының № 2,5,6 нче, Татарстан урамның 1-4 нче, Бакча урамының 1,3,6 нче йортлары).

**3 номерлы бермандатлы Советлар сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 77

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Нырты авылы (Советлар урамының йортлары, Бакча урамының 2,4,5,7,9,11 нчы йортлары).

**4 номерлы бермандатлы Кооператив сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 82

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Нырты авылы (Кооператив урамының йортлары, Пионер урамының 2,3,4,8,11,13,19 нче йортлары).

**5 номерлы бермандатлы Чишмә сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 76

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Нырты авылы (Урман урамыны, Узәк урамы, Пионер урамының 14, 14а, 16 нче йортлары, Бакча урамының 12-33 нче йортлары) Төркәш авылы ( Чишмә урамы, Узәк урамының 1а йорты)

**6 номерлы бермандатлы Узэк сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 84

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Төркәш авылы (Узәк урамының җөп ягы йортлары, Яшел урамы, Узәк урамының 1,11,13 йортлары).

**7 номерлы бермандатлы Бакча сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 85

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Чәбия авылы; Төркәш авылы (Узәк урамының так ягындагы йортлары, 19 йорттан башлап).

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәте**

